Автономная некоммерческая организация
дополнительного профессионального образования «Академия менеджмента»
Муниципальное автономное учреждение дополнительного образования
города Набережные Челны «Детская школа искусств №7»

# «ИННОВАЦИИ И СОХРАНЕНИЕ КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ И ТРАДИЦИЙ КЛАССИЧЕСКОГО ИСКУССТВА КАК ПРИОРИТЕТЫ ХУДОЖЕСТВЕННОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ В ОРГАНИЗАЦИЯХ ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ»

г. Набережные Челны, 2022

Автономная некоммерческая организация
дополнительного профессионального образования «Академия менеджмента»
Муниципальное автономное учреждение дополнительного образования
города Набережные Челны «Детская школа искусств №7»

Республиканский
научно-практический семинар

# «ИННОВАЦИИ И СОХРАНЕНИЕ КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ И ТРАДИЦИЙ КЛАССИЧЕСКОГО ИСКУССТВА КАК ПРИОРИТЕТЫ ХУДОЖЕСТВЕННОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ В ОРГАНИЗАЦИЯХ ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ»

*Сборник материалов*
*Республиканского научно-методического семинара*

**Методические материалы**
**к ДПОП «театральное искусство»**

**УДК 371**

**ББК 74.200.587**

«Инновации и сохранение культурного наследия и традиций классического искусства как приоритеты художественной деятельности в организациях дополнительного образования»: материалы Республиканского научно-практического семинара г. Набережные Челны 14 декабря 2022 года – 291 с.

Составители:
Хаметшина О.В., директор МАУДО «Детская школа искусств №7» г. Набережные Челны
Илларионова И.Н., заместитель директора по МР МАУ ДО «Детская школа искусств №7» г. Набережные Челны

В сборнике представлены материалы Республиканского научно-практического семинара «Инновации и сохранение культурного наследия и традиций классического искусства как приоритеты художественной деятельности в организациях дополнительного образования».

Ответственность за точность цитат, имен, названий и иных сведений, а также за соблюдение законов об интеллектуальной собственности несут авторы публикуемых материалов.

**СОДЕРЖАНИЕ**


| | | |
|---|---|---|
| 1. | Ибрагимова Василя Раифовна,<br>преподаватель по классу театра высшей квалификационной категории<br>МАУ ДО «Детская школа искусств №7», г. Набережные Челны<br>**АКТЕРЛЫК ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УЕН ТЕХНИКАСЫНЫҢ РОЛЕ** | **4** |
| 2. | Мингазова Ильзина Индусовна,<br>преподаватель по классу театра высшей квалификационной категории МАУ ДО «Детская школа искусств №7» г. Набережные Челны<br>**СӨЙЛЭМ ТЕЛЕНДЭ СУЛЫШ АЛУНЫН ЯНА АЛЫМНАРЫ** | **7** |



Ибрагимова Василя Раифовна,

преподаватель по классу театра высшей квалификационной категории

МАУ ДО «Детская школа искусств №7», г. Набережные Челны


## АКТЕРЛЫК ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УЕН ТЕХНИКАСЫНЫҢ РОЛЕ

Выготский Л.С. сәнгать психологиясе эшендә уенның һәм сәнгәтнең тамырдаш булуын ас сызыклый. Икесенендә асылында охшату феномены ята. күзаллау, фантазияләү бу укучыларның һәр берсенә бирелгән. Бөек К.С. Станиславскийда актерларга ышанычны арттыру өчен балалрның уеннарын күзәтергә кушкан. Балалар кемнедер кабатлау белән үзлэрендә ышану көчен арттыралар.

Укучының яшенә карап уеннар гадирәк була, ә инде яшь ускән саен бу уеннар катлаулана. Һәр уенның бала өчен ниндидер мөхим яклары булуы шарт. Театрның синтетик табигате комплексль эшли: әдәби әсәргә йогынты ясый, сәхнә уенының экспрессив чаралары, спектакльнең сәнгате бизәлеше һәм анда кулланучы башка жанрлар. һәр бер балада болар барысыда бар игьтибар, иркенлек,фантазия димәк укытучыга бары тик укучыны дөрес юнәлеш алырлык итеп тәрбияләргә кирәк.

Сюжетлы-рольле уеннарга да бик зур урын бирелә. Бу балаларга бер-берсенә хөрмәт, әдәплелек хисен үстерергә ярдәм итә. Шулай ук дидактик уеннар да ярдәмгә килә. Бу уеннар «Нәрсә артык?», «Читекнең парын тап», «Савыт-сабаны бизә», «Милли киемнәрне бизәү» һ. б. баланың дөрес фикерләү, уйлап табу сәләтен үстерә.

Акыл үсеше белән сөйләм теленең үсеше нык бәйләнгән. Персонажлар сөйләмен сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләгәндә, баланың сүз байлыгы арта, аваз культурасы, интонацияле сөйләү тәрбияләнә. Башкарылачак роль баланы чиста, аңлашылырлык итеп сөйләвен таләп итә. Сәхнәләштерелгән уеннар барышында, бала персонажлар өчен кайгырта, үзен алар урынына куя, булышу ысулларын таба, яхшылык һәм явызлыкка үзенең карашын күрсәтә. Баланы төрле яктан үстерә.

Сәхнәләштерү эшчәнлеген алып барганда, һәр бала үзенең кичерешләрен, тойгыларын, теләкләрен, карашларын гадәти сөйләшкәндә генә түгел, ә чит тыңлаучылар алдында күрсәтә алырлык шартлар тудырырга һәм яшьтән үк өйрәтергә кирәк. Еш кына без киң белемле, сәнгатьле сөйләшә белүчеләрне оялчан икәнен, чит кешеләр алдында югалып калуларын күзәтәбез. Бу проблемалар булмасын өчен, укучыларга театр кую бик зур булышлык күрсәтә. Сәхнәләштерелгән уеннар балаларны шатландыралар. Спектакльләрдә катнашып, балалар тирә-юнь белән, төсләр, авазлар белән танышалар, ә уйланылып куелган сораулар балаларны анализларга, уйланырга, нәтиҗәләр ясарга өйрәтә. Сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү барышында, сизелмичә баланың сүз байлыгы арта, бала чиста, дөрес, аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәнә. Сүзлек формалаша- яңа сүзләр белән баетыла. Әкиятне укып бетергәч, балаларга нинди дә булса җөмләне тәмамларга, кабатларга, эчтәлеген сөйләргә тәкъдим ителә. Аннан кечкенә хикәяләр алына. Әкренләп монологик сойләм генә түгел, ә диалогик сөйләм дә үсә. Аваз культурасы өстендә эшләнелә. Бала күп нәрсәне исендә калдыра. Аның хәтере үсә. Рольне уйный- уйный, бала әкият дөньясына кереп китә, татар телен истә калдыру җиңеләя. Сәхнәләштерү эшчәнлеге күрсәтүенчә, бала ялгышырга мөмкин, ә менә әкият герое ялгышырга тиеш түгел. Шуңа күрә балалар әкият уйнаганда, сүзләрен 2–3 мәртәбә тырышыбрак өйрәнәләр. Аларның бу шөгыльләрдән соң хәтерләре яхшыра. Яраткан геройлар балаларга үрнәк булалар. Сәхнәләштерү эшчәнлеге балаларга проблемалы ситуацияләрне чишәргә булыша- персонаж аркылы оялчанлыкны, кыюсызлыкны бетерергә, сәнгатьле итеп сөйләргә булыша. Рольне уйнау,

баланы башка персонаж алдында чиста, аңлашылырлык итеп аңлатуны таләп итә. Театр бала өчен яп-якты истәлек булып кала.

Акыл үсеше белән сөйләм теленең үсеше нык бәйләнгән. Персонажлар сөйләмен сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләгәндә, баланың сүз байлыгы арта, аваз культурасы, интонацияле сөйләү тәрбияләнә. Сәхнәләштерелгән уеннар барышында, бала персонажлар өчен кайгырта, үзен алар урынына куя, булышу ысулларын таба, яхшылык һәм явызлыкка үзенең карашын күрсәтә. Баланы төрле яктан үстерә.

Өстәмә белем бирү учреждениеләренең төп бурычы балаларны рухи яктан бай, физик яктан сәламәт итеп үстерү. Алар төрле юллар белән тормышка ашырыла. Ә шулар арасында иң әһәмиятлесе – уеннар.

Уен ярдәмендә балаларда зирәклек, оешканлык, коллективта үзеңне тота белү, җитезлек кебек матур сыйфатлар тәрбияләнә.

Уен – ул бала эшчәнлегенең, тормышының аерылгысыз өлеше. Уеннар кешегә яшәве күңеллерәк булсын өчен кирәк. Әйе, җитез, өлгер, зирәк булып үсүе өчен төрле характердагы уеннар балалар тормышының аерылгысыз юлдашы булырга тиеш. Яшь буын тормышның төрле җайсызлыкларына бирешмәскә, уңышсызлыкларыннан җебеп төшмәскә тиеш дибез. Ә моңа яшьтән үк балаларның төрле уеннар уйнаулары аша ирешергә мөмкин.

Дидактик уеннар – балаларны уйланырга, эзләнергә, фикер тупларга, берләштерергә, күнекмәләрне, гадәтләрне тормышта кулланырга өйрәтүче һәм тәрбия бирүче көчле чараларның берсе.

Сүзле уенда катнашучылар күпмедер дәрәҗәдә тырыш, җитез, сабыр да булырга тиеш, кайбер уеннар исә нәниләрдән җыр-биюгә осталык та сорый.

Дидактик уеннар белән җитәкчелек итү зур педагогик осталык, такт таләп итә. Ул 3 төрле юнәлештә алып барыла: дидактик уенга әзерлек, уеннны үткәрү һәм анализ. Уенны башлаганчы, балаларда уйнау теләге, кызыксындыру тудырырга кирәк. Моңа төрле алымнар белән, мәсәлән, табышмаклар, санамышлар, сюрпризлар кулланып ирешергә була.

Уен кагыйдәләрнең төп максаты: балаларның хәрәкәтен, тәртибен оештыру. Кагыйдәләрне саклау балалардан аерым ихтияр көче, иптәшләре белән аралашу сәләтен, уңышсыз нәтиҗәгә ирешкәннән соң туган кире кичерешләрнең җиңә алуны таләп итә, тотнаклылык тәрбияли.

Уен өчен уңайлы шартлар тудыру да игътибар үзәгендә булырга тиеш.

Дидактик уеннарның балаларга акыл тәрбиясе бирүдә роле зур. Уен вакытында баланың сөйләме үсә, сүз байлыгы арта. Чөнки бала бу чакта күпләр белән бәйләнешкә керә, яңадан-яңа сүзләр ишетә һәм үзе дә аларны куллана.

Ритмлы хәрәкәтләр, кызып-кызып яшь тәнне физик яктан чыныктыра. Кыскысы, педагоглар тарафыннан дөрес юнәлеш бирелгәндә, уен, балаларны акыл һәм физик яктан дөрес тәрбияләүгә, бер үк вакытта аларны тормышка әзерләүгә дә ярдәм итә.

Балаларның психологик үзенчәлекләрен истә тотып, уен эшчәнлеген оештыруда берничә төп юнәлешне күрсәтәбез:

-баланың фикерләү, күзаллау сәләтен үстерү;

-уенны баланың һәр төр эшчәнлегенә,режим моментларына кертү;

-һәр баланың характерын, темпераментын, шәхси мөмкинлеген, теләген истә тоту.

Әдәбият


1. Самоукина Н.В. Игры в школе и дома: Психотерапевтические упражнения коррекционные программы. - М- Новая школа,1995.-144 с.

2. Миннуллин Т.А. Сайланма әсәрләр. Избранные произведения. Татарское республиканское издательство «ХЭТЕР», Казань, на татарском языке. 2008.- 479с.

3. Ганелин, Е.Р. Программа обучения детей основам сценического искусства «Школьный театр», 2002.



Мингазова Ильзина Индусовна,

преподаватель по классу театра высшей квалификационной категории

МАУ ДО «Детская школа искусств №7» г. Набережные Челны

## СӨЙЛӘМ ТЕЛЕНДӘ СУЛЫШ АЛУНЫН ЯНА АЛЫМНАРЫ

Сөйләм теле дәресенен төп бурыч булып укучы балаларда сәнгатьне үстерү , сөйләм телен баету, сөйләм вакытында сулышны дөрес итеп алу һәм тамашачыга чиста, матур сойләм белән эсәрне житкерү. Сәнгатж мәктәбенең театр булегендә сөйләм телендә кимчелекләр белән сәхнә теле дәресендә эшлибез. Безнең максат сөйләм телендә булган кимчелекләрне төзәтү, сулышны дөрес алу, сүз байлыгын үстерү – баету, авазларны дөрес әйтергә өйрәтү. Сәхнәдә чыгыш ясап укучыларда эстетик завыкны камилләштерү.

Аларны сәнгатькә тартуда, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә сәхнәләштерү әшчәнлегенең арттыруда сэхнэ теле дэресенен әһәмияте бик зур. Сүз сэңгатендэ иң эһэмиятлесе дөрес сулыш алу. Һәр сулыш дөрес икэн актёрның һэм нэфис сүз сөйлэүченен сөйлэме яхшы була. Сулышны дөрес файдаланырга кирэк. Бала авазларны дөрес итеп эйтсен өчен аны дөрес суларга өйрэтергэ кирэк. Монын өчен борын белэн тирэн сулыш алырга, һаваны экрен генэ чыгарырга кирэк. Сулышны без ритмын һәм тирэнлеген узгэртэ алабыз. Сулыш алунын берничэ төре бар: 1) җилкә сулышы 2) кукрәк сулышы 3) катнаш диафрагматик сулыш. Иң дөрес сулыш алу безнен укучыларда өченче төр максатын тэрбиялэү. Тизэйтемнэр әйткәндә, хәрәкәт иткэндә дэ сулыш дөрес алынырга тиеш.

Аваз – сөйләм органнарынын эшчәнлеге нэтиҗәсендэ барлыкка килә. Кешенен сөйләм барлыкка китерэ торган органнары жыелмасын сөйләм аппараты диләр. Сөйләм аппаратынын өлешләре:

1) Сулыш аппараты: аңа диафрагма, үпкэлэр, бронхлар һэм сулыш юлы керә;
2) Тавыш ярыларыннан һэм кимерчәклэрдән гыйбарәт булган бугаз;
3) Бугаздан өске өлеш ана йоткылык, авыз һэм борын куышлыклары керэ.

Авазлар ясауда барлык органнарда катнаша. Сулыш органнары, авазлар ясалсын өчен һава дулкыны бирәләр, аны төрлечә үзгәртәләр. Сулыш аппараты сулыш алу һәм сулыш чыгару өчен җайланган. Сулыш ике төрле була: аскы һәм

өске сулыш. Өске сулыш булганда үпкәнең өске өлеше генә һава белән тутырыла.

Аскы сулыш алу төрле яклап файдалы. Бу вакытта үпкәнең бөтен өлеше дә, кабыргаларда хәрәкәткә килә.

Сөйләм вакытында үпкәдә һәрвакыт ниндидер күләмдә һава запасы булырга тиеш. Монын өчен укучылар белән махсус кунегүләр эшлибез.

Дөрес сулыш алу сөйләгәндә бик әһәмиятле. Ләкин моның әһәмиятле булуы моның белән генә бетми әле. Без һәр вакыт балаларның сөйләме камил, матур, дөрес булуы өстендә эшләргә тиешбез. Мона дөрес сулыш алу, тавышны рациональ файдалану нәтиҗәсендә генә ирешеп була. Сәхнә теле дәресендә организмны чыныктыру ысуллары арасыннан кызыклы, үзенчәлекле, унайлы формалары булып: сулыш гимнастикасы булып тора.

Сулыш гимнастикасын дөрес ясау кагыйдәләре:

1. Борын белән кыска сулыш алырга, җилкәләрне күтәрмәскә.
2. Сулыш озын һәм салмак булырга тиеш.
3. Сулышны алган саен авыз аша чыгарырга.
4. Сулыш алуны хәрәкәт белән башкарырга.
5. Битләрне кабартмаска.
6. Гимнастиканы утырып та басыпта эшләргә була.

И.С. Краскованын элементар сулыш күнегүләрен куллану бик отышлы: Уч төбенә өр «Шар кабарт».

М. Лазаревның сулыш алу ысулы да бик үзенчәлекле. Аның ысулы һәр авазда аерым чыныктыруга тәэсир итә. Аның ысулы «Терелтүче авазлар» дип атала..

А.Н.Стрельникованың сулыш гимнастикасы ысулы да үзенә бер төрле, анда сулыш хәрәкәтләр белән алып барыла.

Диопазон баскыч кунегүе. Бер баскыч, ике баскыч,оч баскыч, дурт баскыч, биш баскыч белэн югарыга менэбез һэм түбэнгэ төшэбез.

Сулыш күнегүләре сөйләм үсеше өчен әһәмиятле. Авазлар әйтелешенә кирәкле һава агымын формалаштыру өчен укучы сулыш күнегүе аша нечкә агым белән өрергә өйрәнә;

- сөйләм вакытында сулышның житешсезлекләрен жиңәргә ярдәм итә;
- бер фразыны жиңел генә әйтеп бирү өчен һаваны авыз аша салмак кына чыгаруга ирешә;
- сөйләм вакытында дөрес суларга өйрәнү, кимчелеге төзәтелгән авазларны ныгытуда да ярдәм итә.

Дөрес сулыш алу, тавышны рациональ файдалану нәтижәсендә генә сөйләмебезне камил, матур, дөрес булуына ирешеп була.

## ӘДӘБИЯТ:


1. Алексеева М.М., Яшина В.И. Методы развития речи обучения родному языку М.,2000
2. Савкова З.В. Техника звучащего слова. Методического пособие. - М.ВНМЦНТиКПР,1988
3. Хайруллина А.Х. Тел курке - суз. Казан. Мәгариф, 1978-102б.